Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 12**

Шомбыт авылы 2017елның 22 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 2014 елның 13 октябрендәге “Җир салымы турында” 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5 маддәсенең 4 өлеше, 31 бүлеге (икенче өлеш), «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 396-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешенең 3 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Уставы нигезендә,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Шомбыт авыл җирлеге Советының 2014 елның 13октябрендәге “Җир салымы турында” 11 номерлы” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 20.11.2014 ел, № 13, 28.05.2015ел, №11) карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктнытүбәндәгечә үзгәртергә:

«5. Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслаучы документлар салым түләүчеләр тарафыннан үз теләге белән салым органына тапшырыла».

Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт; Шомбыт авылы, Завод урамы, 22 йорт; Шестая Речка авылы, Лесная урамы, 6 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге Башлыгы Н.Е.Сергеев